РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«6» декабря 2023 г. г. Альметьевск № 130

**Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2018 елның 31 маендагы 120 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Башкарма комитеты турында нигезләмә хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 2 ноябрендәге 517-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 4 августындагы 449-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Табигый дәвалау ресурслары, дәвалау-савыктыру урыннары һәм курортлар турында» Федераль законга, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләре үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2023 елның 4 августындагы 469-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм хокукый мониторинг нигезендә,

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2018 елның 31 маендагы 120 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Башкарма комитеты турында нигезләмә хакында»гы карарына (Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2019 елның 16 декабрендәге 182 номерлы, 2021 елның 11 мартындагы 26 номерлы, 2021 елның 17 июнендәге 36 номерлы, 2022 елның 20 апрелендәге 69 номерлы, 2023 елның 29 мартындагы 104 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. карарның 1 кушымтаның 2 бүлегендә «шәһәр Башкарма Комитетының вәкаләтләре»:

1.1.1. 2.2 пунктның 3 пунктчасы унынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- җирле әһәмияттәге аеруча саклана торган табигый территорияләрне куллану һәм саклау өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыра;»;

1.1.2. 2.2 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге эчтәлектәге ундүртенче абзац белән тулыландырырга:

«-әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклауны гамәлгә ашыра һәм муниципаль район милкендәге җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан территорияләргә карата мондый зыянны бетерүне оештыра;»;

1.1.3. 2.2 пунктының 5 пунктчасы унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча җирлекара чаралар оештыра һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнаша, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшли һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшли һәм гамәлгә ашыра ;»;

1.1.4. 2.3 пунктның дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү, муниципаль берәмлек халкына рәсми мәгълүмат җиткерү өчен массакүләм мәгълүмат чарасын һәм (яисә) челтәр басманы гамәлгә куя;».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар, 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керүче 1.1.1 пунктыннан тыш, рәсми рәвештә басылып чыккач (халыкка җиткерелгәч) үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлмәт шәһәр Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Ф.А. Шәйхетдинова).

Шәһәр Башлыгы «АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ» Т.Д. Нагуманов